**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Татар Шуган авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татар Шуганы авылы № 137 25 март 2015 ел.

Татар Шуган авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану
буенча, җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елелның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Татар Шуган авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татар Шуган авылы башкарма комитетының 05 май 2014 елда чыккан 1 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Татар Шуган авыл җирлеге Советының 25 март 2015 елда чыккан 136 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Татар Шуган авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татар Шуган авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 17 май 2015 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда карaласы мәсьәлә:
"Сез, Татар Шуганы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2015 елда 200 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
- көнкүреш калдыкларын, чүпне җыю һәм түгүне оештыру;
- җирлек территорясен төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК

3. Карар районның "Маяк" газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: Г.З.Миясcарова